КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 19 апрель г.Казань № 313

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмаларының физик культура һәм спорт хезмәткәрләренә өстәмә ярдәм күрсәтү турында» 2018 ел, 4 октябрь, 902 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмаларының физик культура һәм спорт хезмәткәрләренә өстәмә ярдәм күрсәтү турында» 2018 ел, 4 октябрь, 902 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«1. Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмаларының физик культура һәм спорт хезмәткәрләренә еллык түләүле өстәмә ялны кушымта нигезендә билгеләргә.»;

карарга кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1998 ел, 4 октябрь, 902 нче карарына кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 19 апрель, 313 нче карары редакциясендә)

Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмаларының еллык түләүле өстәмә ял бирелә торган физик культура һәм спорт хезмәткәрләре исемлеге

| т/б № | Һөнәр исеме* | Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмасы төре | Еллык түләүле өстәмә ял озынлыгы, календарь көн |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Директор | олимпия резервы спорт мәктәбе | 14 |
| | Директор урынбасары (эшчәнлекләре спорт әзерлеге белән бәйле булмаган директор урынбасарларыннан тыш) | | 14 |
| | Тренер | | 14 |
| | Физкультура-спорт оешмаларының инструктор-методисты (өлкән инструктор-методисты) | | 14 |
| | Физик культура буенча инструктор | | 14 |
| | Педагог-оештыручы | | 14 |
| | Педагог-психолог | | 14 |
| 2. | Директор | спорт мәктәбе | 14 |
| | Директор урынбасары (эшчәнлекләре спорт әзерлеге белән бәйле булмаган директор урынбасарларыннан тыш) | | 14 |
| | Тренер | | 14 |
| | Физкультура-спорт оешмаларының инструктор-методисты (өлкән инструктор-методисты) | | 14 |
| | Физик культура буенча инструктор | | 14 |
| | Педагог-оештыручы | | 14 |
| | Педагог-психолог | | 14 |
| 3. | Директор | спорт адаптив | 14 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | Директор урынбасары (эшчәнлекләре спорт әзерлеге белән бәйле булмаган директор урынбасарларыннан тыш) | мәктәбе | |
| | Тренер | | 14 |
| | Адаптив физик культура буенча тренер-укытучы (адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы) | | 14 |
| | Адаптив физик культура буенча инструктор-методист (адаптив физик культура буенча өлкән инструктор-методист) | | 14 |
| | Педагог-оештыручы | | 14 |
| | Педагог-психолог | | 14 |

* Һөнәрләрнең исемнәре тармак белгечләренең һөнәри квалификация төркемнәре нигезендә күрсәтелгән:

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркемнәрен раслау турында» 2012 ел, 27 февраль,165н номерлы боерыгы белән расланган физик культура һәм спорт хезмәткәрләре;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркемнәрен раслау турында» 2008 ел, 5 май,216н номерлы боерыгы белән расланган мәгариф хезмәткәрләре.